РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.02.2020 № 255-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “Күп балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү турында” 2009 елның 24 апрелендәге 330-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Күп балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү максатыннан, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “Күп балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү турында” 2009 елның 24 апрелендәге 330-п номерлы карарына (Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 августындагы 1027-п номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктында “2 000 (ике мең) сум күләмендә” сүзләрен “5 000 (биш мең) сум күләмендә” сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов